Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

13 июль 2022 ел № 160

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 3 февралендәге 37 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты статусы турында нигезләмә хакында»»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 19 ноябрендәге 376-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 60-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында Федераль законнар нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 3 февралендәге 37 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты статусы турында нигезләмә хакында»»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2013 елның 04 июлендәге 306 номерлы, 2015 елның 13 мартындагы 455 номерлы, 2015 елның 10 декабрендәге 40 номерлы, 2017 елның 27 июлендәге 191 номерлы, 2018 елның 11 маендагы 240 номерлы, 2019 елның 25 мартындагы 286 номерлы, 2019 елның 25 октябрендәге 330 номерлы, 2020 елның 12 мартындагы 365 номерлы, 2021 елның 11 мартындагы 46 номерлы, 2021 елның 28 сентябрендәге 83 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарга кушымтаның 19 статьясында «Депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле чикләүләр»:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, федераль законнар белән башкасы билгеләнмәгән булса, Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт вазыйфаларын, башка муниципаль вазыйфаларны, дәүләт яисә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләргә хокуксыз.»;

б) 4 бүлекнең өченче абзацында «, акция» сүзен төшереп калдырырга ;

в) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Муниципаль вазыйфаны, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлары) биләгән зат мәнфәгатьләр конфликтына китергән яисә китерергә мөмкин булган очракта, күрсәтелгән зат үзенә караган кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав

(тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә ышанычлы идарәгә тапшырырга тиеш.».

1.2. 19 статьяның 3 өлешендәге 3 пункттагы а, б пунктчалары нигезләмәләре «Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәр Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль берәмлекләренең сайлау комиссияләрен төзү тәртибенә, аларның вәкаләтләрен һәм статусына, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре әгъзаларының статусына кагылышлы нигезләмәләр «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 60-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 60-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьялары нигезләмәләренә каршы килмәгән өлешендә кулланыла.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советның законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарәгә кагылышлы даими комиссиясенә (Парфилова Н.В.) йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов